Татарстан Республикасы

Аксубай муниципаль районы

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы карары

№ 1 2020 елның 20 октябре

Аксубай муниципаль районы

Иске Кыязлы авыл җирлегендә

гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 2020 елның 30 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Иске Кыязлы авыл мәдәният йорты бинасында (адресы: ТР, Аксубай районы, Иске Кыязлы авылы, Үзәк урамы, 54 нче йорт) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенә кергән Иске Кыязлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздырырга.

2. 2019 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Иске Кыязлы авылы, Сөлчә урамы, 25 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенә кергән Иске Кыязлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Иске Кыязлы авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча 2 өлешкә бүләргә:

1) М. Җәлил, Ленин, Комсомол, Вахитов, Үзәк урамнарда яшәүчеләр.

2) Сөлчә, Тукай, Гагарин, Бакча, Яшьләр урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2020 елда Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүегез һәм акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

1.Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Иске Кыязлы авылы урамнарын төзекләндерү (грунт күтәрү, вак таш салу, вак таш алу, торбалар алу).;

2. Территорияләрне төзекләндерү:

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

-Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты тракторына асылмалы җиһазлар алу.

« ӘЙЕ» "ЮК"

5. Карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Иске Кыязлы авыл җирлеге

Башкарма комитеты җитәкчесе Г.Г.Дәүләтшин